КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 декабрь г.Казань № 1087

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1078 нче; 2022 ел, 29 июнь, 613 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 956 нчы; 2023 ел, 3 февраль, 92 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2023 ел, 28 август, 1033 нче; 2023 ел, 25 сентябрь, 1184 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы» сүзләрен «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» грантын түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

7 пунктта:

беренче абзацта «Министрлык тарафыннан расланган форма буенча» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру тәртибе һәм сроклары;»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Җирле үзидарә органы килешүдә каралган срокларда Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисаплар тапшыра.

Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан, грант алучы дип танылган, килешү белән билгеләнгән грант түләнгән муниципаль мәгариф учреждениеләре саны.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.»;

әлеге карар белән расланган «Туган (татар) тел һәм туган (татар) әдәбият буенча республика олимпиадалары һәм (яки) Татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиада призерларын һәм аларда җиңүчеләрне әзерләгән өчен туган (татар) тел һәм әдәбият укытучыларына ярдәм» гранты турындагы нигезләмәнең 10 пунктындагы унберенче абзацында «сайлап алуны үткәрү датасына кадәрге айның беренче көненә» сүзләрен «заявка бирү датасына кадәр 30 көннән дә иртәрәк булмаган көнгә карата» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Безнең иң яхшы методист» гранты турындагы нигезләмәнең 10 пунктындагы җиденче абзацында «сайлап алуны үткәрү датасына кадәрге айның беренче көненә» сүзләрен «заявка бирү датасына кадәр 30 көннән дә иртәрәк булмаган көнгә карата» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гомуми белем бирү оешмасының иң яхшы педагогы» гранты турындагы нигезләмәдә:

3 пунктның икенче абзацына «мәгариф оешмасы җитәкчесеннән, җитәкчесе урынбасарыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

10 пунктның ундүртенче абзацында «сайлап алуны үткәрү датасына кадәрге айның беренче көненә» сүзләрен «заявка бирү датасына кадәр 30 көннән дә иртәрәк булмаган көнгә карата» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы призерларын һәм анда җиңүчеләрне әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм» гранты турындагы нигезләмәнең 11 пунктындагы алтынчы абзацында «сайлап алуны үткәрү датасына кадәрге айның беренче көненә» сүзләрен «заявка бирү датасына кадәр 30 көннән дә иртәрәк булмаган көнгә карата» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Безнең яңа укытучы» гранты турындагы нигезләмәнең 9 пунктындагы беренче абзацында «Татарстан Республикасы мәгариф белән идарә итү муниципаль органнары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга.

4. Бу карар (әлеге карарның 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин